ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих авылында

2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 27 ноябре №2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең Салих авылында гражданнар җыены нигезендә

Карар

1. 2026 елда авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Салих авыл җирлегендә көндезге бүлектә укучы студентлардан, Салих авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затлардан, тыл ветераннарыннан, I һәм II төркем инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә контракт буенча хәрби хезмәткә кергән йә контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән СВО катнашучыларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (МТЗ 82.1 тракторы өчен кар җыючы сатып алу Салих авылы);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы һәм җәйге вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту, шул исәптән Салих авылында трактор тоту).

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (http://bavly.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru).

Гражданнар җыенында рәислек итүче___________ И. Н. Хәйруллин